| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.03.2016 Алабуга шәһәре №46

Алабуга муниципаль районы Советының «Муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 8 августындагы 121 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар таләпләренә туры китерү максатларында, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «Муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 8 августындагы 121 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. Нигезләмәнең 1 бүлеген түбәндәге эчтәлекле пунктлар белән тулыландырырга:**

«1.3. Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге унитар предприятиеләрне гамәлгә куючы булып тора.

1.4. Муниципаль берәмлек исеменнән унитар предприятиеләр милкен гамәлгә куючының, аның милекчесенең функцияләрен һәм вәкаләтләрен Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасы гамәлгә ашыра.

1.5. Муниципаль мөлкәтнең устав эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле унитар предприятиеләрен беркетү гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.»

1.2. Нигезләмәнең 2 нче бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« **2. Муниципаль предприятиеләр төзү турында карар кабул итү тәртибе**

2.1. Муниципаль предприятиеләр төзү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- хосусыйлаштыру тыелган мөлкәттән файдалану зарурлыгы;
- социаль бурычларны хәл итү максатларында эшчәнлекне гамәлгә ашыру зарурлыгы (шул исәптән, минималь бәяләр буенча билгеле бер товарларны һәм хезмәтләрне гамәлгә ашыру);
- федераль законнарда бары тик муниципаль унитар предприятиеләр өчен генә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

– Россия Федерациясе иминлеген тәэмин итүгә бәйле тармакларда фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру зарурлыгы;
– Россия Федерациясе мәнфәгатьләре өлкәсендәге һәм аның иминлеген тәэмин итүче продукциянең аерым төрләрен эшләү һәм әзерләү зарурлыгы;
– әйләнештән алынган яисә әйләнешкә сәләте чикләнгән аерым төр продукция җитештерү зарурлыгы.

2.2. Муниципаль унитар предприятиене төзү инициаторлары булып түбәндәгеләр тора ала:

- Алабуга муниципаль районы Советы, депутатлар төркеме;

- район Башлыгы, аның урынбасарлары;

- Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары.

2.3. Муниципаль предприятие төзү инициаторлары Алабуга муниципаль районы советына унитар предприятие төзү турында карар проектын юллый, анда предприятиене төзү кирәклеге, аның максаты һәм эшчәнлек төрләре күрсәтелә.

Карар проектына шулай ук унитар предприятие төзүнең техник-икътисади нигезләмәсен үз эченә алган документлар һәм материаллар да теркәлә.

Техник-икътисади яктан нигезләүдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

аларны төзү чыгымнары һәм финанслау чыганаклары, продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерү күләмнәре,

продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүгә чыгымнар, хезмәт күрсәтүләргә тарифлар, көтелгән керем күләме һәм табыш, эш урыннары саны,

унитар предприятиегә тапшыру өчен тәкъдим ителә торган мөлкәт турында мәгълүмат, унитар предприятие төзүгә бәйле бюджет чыгымнары.

2.4. Район Советы эш регламентында билгеләнгән тәртиптә 2.3 пунктында күрсәтелгән документларны һәм аңа кушып бирелә торган материалларны карый.

2.5. Кирәк булса, район Советы (профильле депутат комиссиясе) җирле үзидарәнең башка органнарыннан һәм оешмалардан өстәмә белешмәләр һәм документлар соратып ала.

1.3. **Нигезләмәнең 3 бүлеген түбәндәге эчтәлекле пунктлар белән тулыландырырга:**

«3.7. Төзелә торган унитар предприятие җитәкчесе гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокта һәм тәртиптә юридик затның дәүләт теркәвен һәм аны салым органында исәпкә алуны тәэмин итә.

3.8. Унитар предприятие җитәкчесе вәкаләтле органнарда юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклаучы документлар алынганнан соң өч көн эчендә карый һәм аны салым органында исәпкә кую турында күрсәтелгән документларның күчермәләрен вәкаләтле органга тапшырырга тиеш».

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе Г.Е. Емельянов